Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Олы Шыңар торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР.

28.03.2024 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 17.12.2021ел 29нчы номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлеше) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында карарына таянып, « Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Олы Шыңар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы “2024нче елда Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Олы Шыңар авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 860 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны сарыф итүнең конкрет юнәлешләренә юнәлдерү:
1) “Олы Шыңар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау” 2) "Олы Шыңар авылында инеш ярын тезекләндерү”
3) “Олы Шыңар авылында каптаж өчен җиһазлар сатып алу” турында карарында күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге төрләргә үзгәртү өлешендә:
1) “Олы Шыңар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау”
2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Олы Шыңар авылында инеш ярын төзекләндерү)
3) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Олы Шыңар авылында каптаж өчен җиһазлар сатып алу)” турында 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы мәсьәләсе буенча 2024 елның 28 мартында гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия 278 ке ше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 140 кеше кертелгән. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:: «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 140 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучылардан тавыш бирүче булмады. Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Шыңар авыл җирлегенең Олы Шыңар авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Олы Шыңар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына, карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге төрләргә үзгәртү өлешендә
1) “Олы Шыңар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау”
2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Олы Шыңар авылында инеш ярын төзекләндерү)

3) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Олы Шыңар авылында каптаж өчен җиһазлар сатып алу)"  үзгәрешләр кертү турында" карарны кабул ителгән дип санарга.

4.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов